КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 24 гыйнвар г.Казань № 40

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 2015 ел, 1 июнь, 391 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 сентябрь, 636 нчы, 2017 ел, 15 май, 282 нче, 2018 ел, 5 февраль, 59 нчы, 2018 ел, 4 апрель, 205 нче, 2018 ел, 5 сентябрь, 757 нче, 2019 ел, 27 февраль, 130 нчы, 2019 ел, 2 октябрь, 886 нчы, 2019 ел, 31 октябрь, 987 нче, 2019 ел, 25 декабрь, 1191 нче, 2020 ел, 2 март, 155 нче, 2021 ел, 12 гыйнвар, 7 нче, 2021 ел, 23 декабрь, 1274 нче, 2023 ел, 30 гыйнвар, 70 нче, 2023 ел, 30 март, 380 нче, 2023 ел, 2 ноябрь, 1410 нчы, 2023 ел, 29 декабрь, 1741 нче, 2024 ел, 27 февраль, 100 нче, 2024 ел, 30 декабрь, 1277 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «җирле әһәмияттәге мәсьәләләр» сүзләрен «халыкның тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләре (җирле әһәмияттәге мәсьәләләр)» сүзләренә алмаштырырга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 27 статьясы» сүзләрен ««Бердәм гавами хакимият системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль законның 50 статьясы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктның өченче абзацында «җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне» сүзләрен «халыкның тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен (җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне)» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктның икенче абзацында «җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне» сүзләрен «халыкның тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү мәсьәләләрен (җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне)» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктта «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 27 статьясы» сүзләрен ««Бердәм гавами хакимият системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы федераль законның 50 статьясы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын үткәрү буенча конкурс комиссиясе составында:

конкурс комиссиясе составыннан Р.В.Гайнетдиновны, О.А.Кисапованы, С.С.Сираҗиеваны чыгарырга;

конкурс комиссиясе составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Анфимова Алла Леонидовнаны | Татарстан Республикасы финанс министры урынбасарын |
| Насыртдинов Олег Рәшит улын | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгын |
| Шәмсиев Айрат Дөлфәт улын | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасарын. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» республика конкурсы турында нигезләмәгә 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 ел, 24 гыйнвар, 40 нчы карары редакциясендә)

Территорияләрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләр эшли торган муниципаль берәмлекләрнең конкурс төркемнәре

| Төркемнәр | Муниципаль берәмлек исеме | 2024 елның 2 ноябренә территориаль иҗтимагый үзидарәләр саны | Заявкаларның максималь саны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| I төркем – шәһәр округлары | Казан шәһәре | 79 | 39 |
| | Чаллы шәһәре | 80 | 40 |
| | Барлыгы | 159 | 79 |
| II төркем – халкы 60 мең кешедән күбрәк булган шәһәр җирлекләре | Әлмәт шәһәре | 36 | 18 |
| | Алабуга шәһәре | 18 | 9 |
| | Зеленодольск шәһәре | 4 | 2 |
| | Лениногорск шәһәре | 13 | 7 |
| | Түбән Кама шәһәре | 27 | 14 |
| | Чистай шәһәре | 8 | 4 |
| | Барлыгы | 106 | 54 |
| III төркем – халкы 60 мең кешегә кадәр булган шәһәр җирлекләре һәм авыл җирлекләре | Әгерҗе шәһәре | 7 | 4 |
| | Азнакай шәһәре, Азнакай муниципаль районы составына керә торган Актүбә шәһәр тибындагы поселогы | 17 | 9 |
| | Алексеевск муниципаль районы составына керә торган Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы | 3 | 2 |
| | Арча шәһәре | 5 | 3 |
| | Баулы шәһәре һәм Баулы муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 25 | 13 |
| | Балтач муниципаль районы составына керә торган Балтач шәһәр тибындагы поселогы | 1 | 1 |
| | Буа шәһәре | 6 | 3 |
| | Чүпрәле муниципаль районы составына керә торган Иске Чүпрәле авыл җирлеге | 1 | 1 |
| | Алабуга муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 15 | 8 |
| | Зәй шәһәре | 13 | 7 |
| | Зеленодольск муниципаль районы составына керә торган Васильево | 12 | 6 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | шәһәр тибындагы поселогы, Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы һәм авыл җирлекләре | | |
| | Кама Тамагы муниципаль районы составына керә торган барлык шәһәр һәм авыл җирлекләре | 21 | 11 |
| | Кукмара шәһәре | 8 | 4 |
| | Лаеш шәһәре һәм Лаеш муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 29 | 15 |
| | Мамадыш шәһәре, Мамадыш муниципаль районы составына керә торган Красная Горка авыл җирлеге | 9 | 5 |
| | Менделеевск шәһәре | 5 | 3 |
| | Минзәлә шәһәре | 7 | 4 |
| | Түбән Кама муниципаль районы составына керә торган Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы | 3 | 2 |
| | Нурлат шәһәре һәм Нурлат муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 13 | 7 |
| | Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы | 9 | 5 |
| | Сарман муниципаль районы составына керә торган Җәлил штп. һәм авыл җирлекләре | 5 | 3 |
| | Болгар шәһәре | 1 | 1 |
| | Тәтеш шәһәре | 5 | 3 |
| | Тукай муниципаль районы составына керә торган авыл җирлекләре | 5 | 3 |
| | Ютазы муниципаль районы составына керә торган Урыссу шәһәр тибындагы поселогы | 32 | 16 |
| | Барлыгы | 257 | 139 |
| Барысы | | 522 | 272 |

___________________